**КАРАР**

**2025 елның 19 ноябрендәге** **1 номерлы**

**Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга Авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ташлы-елга Авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә:

Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Ташлы-Елга Авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән тыш, 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә, 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк булган, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары.

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;

торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү..

3. Карарны мәгълүмат стендларында, Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: www.pravo.tatarstan.ru,

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кәркәүч авыл
җирлеге башлыгы

М.Ф.Зайнутдинов